

# РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН ИҖАТЫНДА БАЛАЧАК ИЛЕ.

Эшне башкарды: Исламова
Эльвира Мәүлетдин кызы

- Шагыйрь
- Журналист
- Татарстан Дәүләт Советы депутаты
- Мәдәният һәм милли мәсьәләләр буенча комиссия рәисе

Роберт Мөгаллим улы Миңнуллин 1948 елның 1 августында Башкортстан Республикасының Илеш районы Нәҗеде авылында дөньяга килгән.


**Р.Миңнуллин**

Бөркетләр
Тауда туа,
Батырлар
Яуда туа!
Шагыйрь булсаң, дөрләп кенә,
Янып-көеп кенә була.
Шагыйрь гади була алмый,
Шагыйрь бөек кенә була!

# Р.Миңнуллин – нәниләр шагыйре.





# „Энекәш кирәк миңа”

Әтиләр бит ничә кабат,
Алабыз,дип алдыйлар
Бердәнбер малайларына
Бер энекәш алмыйлар.




**Шигырьләрдәге кисәтү, үпкә булып яңгыраган сүзләр нигезендә тормыш хакыйкате ята.**

Анның ижатыннан бала үзенең шәхес булуын ассызыклау мөмкинлеген ала.

**„Юк инде...”**

**-Кимә,тимә,тотынма,**
**Килмә,көлмә,утырма,**
**Япма,ятма,котрма!..**
**Бу сүзләрдән туйдым мин,**
**Үземә чик куйдым мин...**

# ,,Без сугыш теләмибез!” циклы.

Сугыш теләми балалар,
Бәбиләр һәм сабыйлар.
Нәни җәнлекләр дә сугыш
Кирәкми дип саныйлар.
,,Сугыш”дигән сүз үзе дә
Кыса безнең сулышны.
Зурлар белән крокодиллар
Телидер ул сугышны.

# Иҗатта төп ике үзәк-хәзерге мизгел һәм мәңгелек,тарих белән бәйле тормыш фәлсәфәсе.

Безнең йортның подъездына
Ни генә язылмаган,
Ничек кенә бозылмаган,
Ни генә сызылмаган.
... Имештер, бабаларының
Эшен дәвам итәләр...
Аларның бабалары да
Кереп дошман күзенә
Исемнәрен язып кайткан
Рейхстагның үзенә!

**Роберт Миңнуллин күп кенә шигырьләрендә табигатькә, кош-кортлар,хайваннар дөньясына мөрәҗәгать итә, аларны җанландыра.**

Алар бит чи-чи дигән
Яңа җыр өйрәнәләр,-

1.Роберт Миңнуллин-олы шәхес.

2.Аның балалар өчен иҗат ителгән шигырьләре ата-аналар өчен дә файдалы чара булып тора.

3.Аның шигырьләре балаларны тәрбияләүдә зур әһәмияткә ия.

**Кешеләргә без яхшылык эшлик!**
**Эшлшмәсәк-гарьлек.**
**Тик яхшылык эшләү җиңел түгел,**
**Ул-зур фидаркарьлек!**
**Барыбыз да яхшылыкка мохтаҗ,**
**Бу заманда бигрәк,**
**Яхшылыкны эшләү җиңел түгел,**
**Ә эшләргә кирәк!**
**(,,Яхшылык")**